Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Әхмәт авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

13 ноябрь 2020 ел № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2020 елның 13 ноябрендә узган: «2021 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Әхмәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, сугышчан хәрәкәтләр ветераннары, 75 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Әхмәт авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- Әхмәт авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен норматив хәлгә китерү;
- МТЗ-82 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 174 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 74 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 62 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 12 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Әхмәт авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «2021 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Әхмәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, сугышчан хәрәкәтләр ветераннары, 75 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан кала, балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Әхмәт авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- Әхмәт авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен норматив хәлгә китерү;
- МТЗ-82 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль

районының Әхмәт авыл җирлегенең Әхмәт авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Х. Шәйхетдинов

Әхмәт авыл җирлеге башлыгы: Р.Х. Шәйхетдинов